ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

№ 79 от 07.11.2025

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының "Карасу авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрүне билгеләү турында

Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Аксубай муниципаль районы Башлыгы Аксубай муниципаль районы Уставы нигезендә карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының "Карасу авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрүне билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны оештыручы - коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев;
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.И. Ислямов;
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.Р. Сәрвартдинова;
- Аксубай муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М.А.Габдрахманов;
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Карасы авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Фәхрутдинов.

3. Җәмәгать тыңлауларын оештыручы җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә җәмәгать тыңлауларын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итә.

4. Ачык тыңлаулар үткәрү вакытын билгеләү - аларны үткәрү турында кызыксынган затларга хәбәр иткән мизгелдән алып ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында нәтиҗә бастырылган көнгә кадәр. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү вакыты бер айдан артмаска тиеш.

5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган җәмәгать фикер алышулары башлануы турында хәбәр әзерләсен.

6. Бу карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.rn) һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (https://aksubayevo.tatarstan.ru/) бастырырга.

7. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Район башлыгы: А.М.Мингулов